СОВЕТ МОРТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МОРТ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ с. Морты КАРАР

№ 28 28 май 2021 ел

**"Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Морт авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 елларның план чорына бюджеты турында"гы 16.12.2020 елнын 14 номерлы Алабуга муниципаль районы Морт Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Алабуга муниципаль районы Морт авыл җирлегендә бюджет процессы турында» гы Положение нигезендә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 статьясына таянып, Морт авыл җирлеге Советы

Карар итте:

1. Морт авыл җирлеге Советының 2020 елның 16 декабрендәге 14 номерлы " Морт авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 елларның планлы чорына бюджеты турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

*1 өлеш*

1 пунктта «2 101,7» санын «2 376,92» санына алмаштырырга»;

2 пунктта «2 101,7» санын «2 490,7" санына алмаштырырга»;

3 пунктта «0» санын «113,8»санына алмаштырырга.

*3 өлеш*

«2021 елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Морт авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» 1 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә;

2) 3 статьяда:

2 нче кушымтаны «2021 елга Морт авыл җирлеге бюджетының фаразланган керемнәре күләмнәре» яңа редакциядә бәян итәргә;

3) 4 статьяда:

*1 өлеш*

3 нче кушымтаны «Алабуга муниципаль районы Морт авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеге " яңа редакциядә бәян итәргә;

4) 5 статьяда:

*1 өлеш*

5 нче кушымтаны «2021 елга авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» яңа редакциядә бәян итәргә;

*2 өлеш*

6 нчы кушымтаны «2021 елга бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре), төркемнәре буенча җирлек бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлү» яңа редакциядә бәян итәргә;

*3 өлеш*

7 нче кушымтаны «2021 елга бюджет чыгымнарының максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча җирлек бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлү» яңа редакциядә бәян итәргә;

5) түбәндәге эчтәлекле 9 статья өстәргә:

«2021 елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертларның күләмен, әлеге карарның 9 нчы кушымтасы нигезендә, 37,6 мең сум күләмендә бүлеп, исәпкә алырга»;

2021 елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар " 9 нчы кушымтасын өстәргә»;

6) 9 – 12 статьяларны 10 – 13 статьялар белән санарга.

2. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыгарга тиеш.

Рәисе Ф.Ф.Закиров